РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАЛАНДЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

Гагарина ул., д. 4, с. Баландыш, 422098
тел. (факс): (84360) 55-6-10,
E-mail: Bln.Tul@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАЛАНДЫШ АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ**

Гагарин ур., 4 нче йорт, Баландыш авылы, 42209
тел. (факс): (84360) 55-6-10
E-mail: Bln.Tul@tatar.ru

ОКПО 93053609 ОГРН 1061675010154 ИНН/КПП 1619004362/161901001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**“13” август 2020 ел**

**КАРАР**
**№ 11**

Теләче муниципаль районының Баландыш авыл җирлеге территориясендә дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Президентын һәм Баландыш авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары депутатларын сайлаулар буенча сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннар билгеләү турында

«2020 елның 13 сентябрендә җирле үзидарәнең вәкиллекле органнары депутатларын сайлауларда сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен һәр сайлау участогы территориясендә махсус урыннар бүлеп бирү һәм җиһазлау турында җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итү хакында» Татарстан Республикасы Теләче районының 2020 елның 28 июлендәге 14/22 номерлы территориаль сайлау комиссиясе карарын карап, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 64 статьясындагы 8 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Баландыш авыл җирлеге Башкарма комитеты,

## КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районының Баландыш авыл җирлеге территориясендә дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Президентын һәм Баландыш авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары депутатларын сайлаулар буенча сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен түбәндәге махсус урыннарны билгеләргә:

- Баландыш авылы, Киров урамы, шәхси эшмәкәр “Хакимова” кибет янында мәгълүмат стенды;

- Урта Мишә авылы, Мәскәү урамы, клуб бинасы янында мәгълүмат стенды.

2. Баландыш авыл җирлеге башкарма комитетының «Теләче муниципаль районы Баландыш авыл җирлеге территориясендә алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советына депутатлар сайлау буенча сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннар билгеләү турында» 2019 елның 25 июль № 20 карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Теләче районы территориаль сайлау комиссиясенә җибәрергә.

4. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

5. Әлеге карарны Баландыш авыл җирлегенең мәгълүмат стендында түбәндәге адрес буенча : Баландыш авылы, Гагарин урамы,4 йорт, Баландыш авыл җирлеге башкарма комитетының административ бинасында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Теләче муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

Р.Ш.Мухаметшин